ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.12.2019 г.Мензелинск № 1136

Минзәлә муниципаль районында
2019-2021 елларга мәктәпкәчә яшьтәгеләрнең өлкән баскычында һәм гомуми белем алуның башлангыч баскычында белем алучылар өчен
“БАЛАЧАК АКАДЕМИЯСЕ”
өстәмә белем бирү үсеш программасын
раслау турында

1. Минзәлә муниципаль районында 2019-2021 елларга мәктәпкәчә яшьтәгеләрнең өлкән баскычында һәм гомуми белем алуның башлангыч баскычында белем алучылар өчен “БАЛАЧАК АКАДЕМИЯСЕ” өстәмә белем бирү үсеш программасын расларга.
2. Гамәлдәге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Н.Г.Бикеевага йөкләргә.

Җитәкче К.Р. Нәҗмиев

**Минзәлә муниципаль районында**
**2019-2021 елларга мәктәпкәчә яшьтәгеләрнең өлкән баскычында һәм гомуми белем алуның башлангыч баскычында белем алучылар өчен өстәмә белем бирү үсеш программалары**

**ПАСПОРТЫ**

| | |
|---|---|
| **Программа аталышы** | Минзәлә муниципаль районында 2019-2021 елларга мәктәпкәчә яшьтәгеләрнең өлкән баскычында һәм гомуми белем алуның башлангыч баскычында белем алучылар өчен өстәмә белем бирү үсеш программасы |
| **Программаны эшкәртү өчен нигезләр** | • Россия Федерациясе Конституциясе<br>• 2012 елның декабрендәге "Россия Федерациясендә мәгариф турында"гы №273-ФЗ Федераль Законы. БМОның Бала хокуклары турында конвенциясе, 1989 ел.<br>• 2025 елга кадәр Россия Федерациясендә Мәгарифнең милли доктринасы<br>• Балаларга өстәмә белем бирүне үстерү концепциясе (04.09.2014 елдагы Россия Федерациясенең №1726-р күрсәтмәсе белән расланган)<br>• "2014-2020 елларга Татарстан Республикасында мәгариф һәм фән үсеше" дәүләт программасы<br>• "Балалар өчен алу мөмкин булган өстәмә белем" РФ проекты<br>• Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2018 елның 9 ноябрендәге "Өстәмә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында"гы №196 Боерыгы |
| **Программага заказ бирүче** | • ТР Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты |
| **Төп эшкәртүчеләр** | • ТР Минзәлә муниципаль районының "Мәгариф бүлеге" МКУ |
| **Программаны бергә башкаручылар** | -Муса Җәлил исемендәге Минзәлә педагогия көллияте ДАҺБУ<br>-Минзәлә муниципаль районы буенча ЭЭМның ЮХИДИ бүлекчәсе<br>-ТР ДОСААФ Минзәлә автомобиль мәктәбе<br>ТР Минзәлә муниципаль районының "Үзәкләштерелгән китапханәсе" |

| | |
|---|---|
| **нәтиҗәләре** | дәрәҗәсендә өстәмә белем бирү программаларына җәлеп итү;<br>- мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының белем алучыларның техник, театраль эшчәнлеге, хореография, полилингваль белем бирү, юл йөрү кагыйдәләрен өйрәнү, физкультура һәм спорт белем бирү программалары буенча өстәмә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия алу;<br>- яңа уку планнарын тормышка ашыру кысаларындаөстәмә белем бирү программаларын индерү буенча шәһәр һәм район белем бирү оешмалары белән үзара аралашу һәм хезмәттәшлек оештыру, гомуми белем бирү программаларын һәм өстәмә белем бирү программаларын интеграцияләү, белем алучыларның буш вакытын оештыруда мәктәпләр белән хезмәттәшлекнең яңа формаларын куллану һәм кызыксынулар буенча берләшмәләрдә аларны системалы дәресләргә җәлеп итү;<br>- бюджеттан тыш чараларны җәлеп итү механизмын камилләштерү: предприятиеләрнең, коммерцияле структураларның хәйрия акчаларын, хәйриядән кергән акчаларны җәлеп итү; учреждениеләрдә попечительлек эшчәнлеген үстерү; |
| **Программаның үтәлешенә контрольне оештыру системасы** | Текстлы отчѐтлар, сайтларда һәм массакүләм мәгълүмат чараларында публикацияләр, эш тәҗрибәсе белән уртаклашу |

## Өстәмә белем бирү үсешенең концептуаль нигезләре

Балаларга өстәмә белем бирүнең заманча сферасындагы эволюция белем бирү эшчәнлегендә яңа формалар, ысуллар һәм чаралар эзләү белән бәйле, ә бу практикада балаларга өстәмә белем бирү педагогикасының инновацияле потенциалын мөмкин кадәр тулырак гамәлгә ашыру өчен шартларны оештыру зарурлыгын күздә тота.

Балаларга заманча өстәмә белем бирүнең төп бурычы – балага үз-үзен үстерү, үз-үзен күрсәтү, үз-үзен оештыру, иҗат өчен шартлар тудыру, аңа тормышта (шәхси, социаль һәм һөнәри) үз-үзен табуда ярдәм итү.

Балаларга өстәмә белем бирүне модернизацияләү сәясәтенең максаты балаларны һәм яшьләрне җәмгыятьнең социаль-иктисадый, сәяси, фәнни-техник, мәдәни тормышына актив җәлеп итү, кеше ресурсларының көндәшлеккә сәләтлелеген тәэмин итүдән гыйбарәт. Балаларга өстәмә белем бирү системасындагы үзгәрешләр белем бирү эшчәнлегенең сыйфатын күтәрүгә төгәл юнәлгәнлек белән системалы фәнни-методик ориентирларга нигезләнергә тиеш.

Өстәмә белем бирү бүгенге көндә дәүләт, шәһәр, район, төбәк, һөнәри берләшмәләр (шул исәптән, педагогик), ата-аналар кебек күптөрле төркемнәрнең мәнфәгатьләре кисешә торган өлкәгә әверелә.

Өстәмәлелек идеясе мәгарифне киң социаль-мәдәни контекстына кертү, ә өстәмә белем бирүнең үзен район үсешенә карата тикшерү зарурлыгына бәйле рәвештә карала башлый.

Бүгенге көндә балаларга өстәмә белем бирү катлаулы чор кичерә.

Кабул ителгән ФГОС якын килүләр өстәмә белем бирүгә турыдан-туры тәэсир итә.

Мәгарифкә ФГОС индерү балаларга өстәмә белем бирүне иярчен (икенчел) буларак кабул итү стереотибын җимерергә, ә бу балага белем бирү, тәрбия һәм үсешне бердәм процесска берләштерү мөмкинлегенә объектив рәвештә ия булуын аңлатырга ярдәм итә ала.

| | |
|---|---|
| | -С.Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт драма театры<br>- ТР Минзәлә муниципаль районының Минзәлә шәһәре РМЙ МБУК<br>-ТР, Минзәлә шәһәре Балалар иҗат йорты МБУ БО<br>-ТР Минзәлә муниципаль районының “Юбилейный”Спорт мәктәбе” МБУ<br>- Балалар сәнгать мәктәбе |
| **Программада катнашучылар** | Минзәлә муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү оешмалары, 1 нче, 2 нче, 3 нче урта мәктәпләр МББУ, “Гимназия” МББУ. |
| **Программаны гамәлгә ашыру срогы** | 2019-2021 еллар |
| **Программаның максаты** | Балаларга өстәмә белем бирүне үстерү тактикасын, стратегиясен эшкәртү, һәр гражданинның, җәмгыятьнең заманча ихтыяҗларына, икътисад үсеше таләпләренә тәңгәл килүче сыйфатлы өстәмә белемнең мөмкинлекләрен күтәрү өчен шартлар тудыру |
| **Программаның бурычлары** | - үзгәрүче тормыш шартларына балаларның социаль адаптация дәрәҗәсен үзгәртү;<br>- балаларның уңышлы социальләшүе;<br>- тәрбияләнүчеләрнең мөстәкыйль гражданлык, әхлакый сайлавына, шәхси иҗади үзмәшгульлеккә әзерлекне формалаштыру;<br>- социаль җаваплылык күрсәтү, аңлы тормыш билгеләнеше һәм һөнәр сайлау;<br>- сәләтле балаларга, талантлы яшьләргә ярдәм, аларны ачыклау системасын камилләштерү;<br>- өстәмә белем бирү системасы үсешендә ведомствоара хезмәттәшлекне тәэмин итү; гаилә һәм район җәмәгатьчелеге белән социаль партнерлыкны активлаштыру;<br>-өстәмә белем бирүне, шул исәптән,белем бирү оешмаларының өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга җәлеп итү юлы белән авыл җирлегендә яшәүчеләр өчен, шулай ук спорт, мәдәният, фәнни оешмалар, иҗтимагый оешмалар һәм икътисадның реаль секторы оешмаларын һәркем ала алырлык итүне күтәрү;<br>- белем алучыларның техник, театраль эшчәнлеген, хореографияне, полилингваль белем бирүне, юл йөрү кагыйдәләрен өйрәнүне, физкультура һәм спортны үстерү;<br>-конкурслар һәм олимпиадалар системасын үстерү юлы белән сәләтле балаларга ярдәм йөзеннән инновацияле мәйданчыклар формалаштыру;<br>- педагогларның квалификациясен күтәрү һәм һөнәри яктан кабаттан әзерләү;<br>-педагогларның һәм өстәмә белем бирү өлкәсендә башка катнашучыларның һөнәри осталыгын һәм компетенция дәрәҗәсен үстерү;<br>-инфраструктураны, балаларга өстәмә белем бирү җиһазларын һәм белем бирү чараларын яңарту;<br>-балалар бакчасы-мәктәп күчә баруын гамәлгә ашыру |
| **Программаның көтелгән** | - 5 яшьтән 8 яшькә кадәр балаларның кимендә 85%ы |

**Минзәлә муниципаль районында**
**2019-2021 елларга мәктәпкәчә яшьтәгеләрнең өлкән баскычында һәм гомуми белем алуның башлангыч баскычында белем алучылар өчен**
“БАЛАЧАК АКАДЕМИЯСЕ”
**өстәмә белем бирү үсеш программасы**

Минзәлә - 2019 ел.

Балаларга өстәмә белем бирү яңа ФГОСны гамәлгә ашыру өчен мәктәпкә күп нәрсә бирә ала:
-баланың шәхси һәм метапредмет нәтиҗәләренә ориентлашкан белем алу маршрутын шәхсән төзү мөмкинлеген;
- эшчәнлек төрләрендә (сәнгать, техник, спорт, полилингваль, театр, Юл йөрү кагыйдәләре) балаларга өстәмә белем бирүнең тар юнәлешләрендә белгечләрне;
-өстәмә белем бирү программаларын һәм дәрестән тыш эшчәнлекне сыйфатлы гамәлгә ашыру өчен матди-техник базаны;
-гомуми һәм өстәмә белемне интеграцияләү процессларына методик ярдәм күрсәтү, иҗади мөмкинлекләрне үстерүнең, профильле белем бирүнең уникаль педагогик технологияләре;
- сәләтле балаларга һәм башка категориягә керүче балаларга (авыр, сәламәтлек буенча мөмкинлекләре чикләнгән) ярдәм итү мөмкинлекләре; социумда эшләү мөмкинлекләре, балаларның социаль иҗаты; балаларның каникуляр вакытын оештыру; рухи-әхлакый тәрбия, сәламәт яшәү рәвешен , балалар үзидарәсен, коррекцион эш, мохитның негатив күренешләрен профилактикалау мөмкинлекләре.
Заманча этапта балаларга өстәмә белем бирүне үстерү факторлары түбәндәгеләр:
- балаларга өстәмә белем бирү эчтәлеген камилләштерү;
- балаларга өстәмә белем бирү системасында инновацияле эшчәнлек;
-балаларга өстәмә белем бирүгә комплекслы якын килү;
- мәгълүмати һәм программа-методик тәэмин ителеш;
- балаларга база, һөнәри һәм өстәмә белем бирүне интеграцияләү;
- фәнни-педагогик иҗат;
- өстәмә белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренең һәм педагогларының һөнәри осталыгын күтәрү;
- балаларга өстәмә белем бирү белән идарә итүне камилләштерү.
Өстәмә белем бирү муниципаль системасын үстерү “заманча социаль-икътисадый шартларда шәхес өчен һәм җәмгыять өчен роле кискен артучы өзлексез белем бирү системасы звеносы, белем бирү системасын камилләштерүнең гомуми стратегиясенең аерылгысыз компоненты” булып тора.
Заманча социаль-икътисадый шартларда ведомствоара һәм эчке ведомство дәрәҗәсендә ресурслар кооперациясе принципларын һәм механизмнарын файдалану, фән, мәдәният, спортның төрле тармакларыннан югары квалификацияле белгечләрне җәлеп итү, җәмгыятьнең даими үзгәрүчән ихтыяҗлары һәм стабиль булмаган икътисадый үсеш шартларында дәүләтнең артып торучы ихтыяҗлары нигезендә программа кырын һәм матди-техник базаны яңарту чиксез зарур.
Килеп туган шартларда асылда барлыкка килгән практика буенча өстәмә белем бирүнең ике перспектив моделен методик яктан һәм сак эшкәртү зарур булып тора – “белем бирү пространствосын интеграцияләү: мәктәптә өстәмә белем бирү һәм класстан тыш эшчәнлек” һәм “мәктәптән тыш өстәмә белем бирү”.
Моның өчен кызыксынган барлык якларның катнашуы, көчләрнең һәм ресурсларның консолидациясе, максатларны һәм бурычларны төгәл кую, механизмнарны билгеләү һәм чынлыкта тиешле шартлар тудыру таләп ителә, ә бу үз чиратында иң яхшы традицияләрне саклап, балаларга өстәмә белем бирүнең яңа сыйфатлы дәрәҗәсенә күчү һәм замана таләпләренә лаеклы җавап бирү мөмкинлеге бирә.

Илдә баручы социаль-икътисадый үзгәрешләр балаларга өстәмә белем бирү ролен актуальләштерделәр һәм замана таләпләре һәм җәмгыять ихтыяҗлары нигезендә аны камилләштерү зарурлыгы шартын куйдылар. Белем бирүнең муниципаль системасында балаларга өстәмә белем бирүне үстерү бурычларын билгеләргә ярдәм итүче төп идеяләр:

•

балаларның барлык төркеме һәм барлык катламнары өчен сыйфатлы өстәмә белем бирү мөмкинлеген тәэмин итү;

•

мөмкинлекләр киңлеге һәм үсешнең хосусый траекториясен сайлау буларак белем бирү хезмәтләренең киң спектрын күрсәтү;

•

гомуми белем бирү мәктәпләре базасында бердәм белем бирү киңлеген булдыру өчен гомуми һәм өстәмә белем бирүне интеграцияләү;

•

үсеш алган инфраструктуралы һәм югары дәрәҗәдә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга ориентлашкан балаларга өстәмә белем бирү оешмаларының яңа типларын булдыру хисабына көндәшлеккә сәләтле белем бирү мохитын активизацияләү.

Балаларга өстәмә белем бирү гомуми белем бирү системасын “тулыландырырга”, аны яхшыртырга һәм танып белү мотивациясен тәэмин итеп, “бөтен гомер буена укырга” күнекмәсен формалаштыру һәм шәхес үсешенең белем бирү траекториясен ирекле сайлау мөмкинлеге биреп, белем бирү альтернативалары системасын шулай төзергә мөмкинлек бирә.
Өстәмә белем бирү үсеше Концепциясе нигезендә, өстәмә белем бирүнең муниципаль системасы үсешенең төп юнәлешләренә түбәндәгеләрне кертергә була:

***1. Балаларның барлык катламы һәм төркемнәре өчен өстәмә белем бирүнең һәркем алырлык булуын һәм сыйфатын тәэмин итү.***

Балаларга өстәмә белем бирү өлкәсендә иң яхшы традицияләрне саклау нигезендә һәм халыкның үзгәрүчән ихтыяҗы нигезендә эшчәнлекнең төрле юнәлешләре буенча социаль гарантияләрне тәэмин итү бүгенге көндә белем бирү сәясәтенең өстенлекле юнәлешләренең берсе булып тора.
Система һәрбер балага эшчәнлек юнәлеше төрен, программа профилен, аны үзләштерү вакытын һәм педагогны ирекле сайлауда тигез мөмкинлекләр тәэмин итүче җитәрлек шартларны тудыру һәм үтәүне таләп итә.
Укучыларны өстәмә белем бирү программалары белән колачлавын күтәрү исәпкә алуның яңа механизмнарын, мониторингның электрон чараларын, ә иң мөһиме, статистик исәпкә алуның үтәкүренмәле кагыйдәләрен белем бирү оешмасы дәрәҗәсендә дә, район дәрәҗәсендә дә иңдерелүен таләп итә.
Сыйфат һәм хезмәтләр спектры турында объектив күзаллау булдыру өчен аның үсешенең актуаль юнәлешләре буенча сыйфатның мониторинг тикшеренүләре системасын оештыру файдалы.

***2. Балаларга өстәмә белем бирүнең эчтәлеген, формаларын һәм технологияләрен балаларның кызыксынуы гаиләнең һәм җәмгыятьнең ихтыяҗлары нигезендә яңарту.***

Балаларга өстәмә белем бирүнең эчтәлеген, формаларын һәм технологияләрен төбәкнең социаль-мәдәни, икътисадый, сәяси үсеше нигезендә яңарту дәүләтнең белем бирү сәясәтенең әһәмиятле юнәлеше булып тора: әлеге өлкәне модернизацияләү яңа өстәмә гомуми белем бирү программаларын эшкәртү һәм гамәлгә ашыру хисабына, шулай ук мәгълүмати технологияләр куллану, эшчәнлекне оештыруның дистанцион һәм челтәрле формалары хисабына югары технологияле белем бирү мохиты булдыру аша башкарыла.
Белем бирү процессында кулланыла торган өстәмә белем бирүнең эчтәлеге, формалары һәм технологияләре укучының культуралы һәм мөстәкыйль шәхесе барлыкка килсен өчен күп үлчәүле, вариатив, ирекле киңлек булдыруга ориентлашкан булырга тиеш.
Ә яңа буынның өстәмә белем бирү программалары үзләре төрле дәрәҗәдә катлаулы булырга һәм педагогка балалар төркеме яки аерым бала белән эшләү өчен оптималь вариант табарга мөмкинлек бирергә тиеш.
Әлеге юнәлешне гамәлгә ашыру шул исәптән үз эченә:

1) өстәмә белем бирүне күрсәтү буенча хезмәтләр эчтәлеген яңартуны тәэмин итү механизмнарын формалаштыру, аларның халыкның ихтыяҗына һәм район үсеше бурычларына тәңгәл килүе, белем бирү процессының нәтиҗәлелеген күтәрүне ала, ә төгәлрәк:
• нәтиҗәле ведомствоара һәм ведомство эчендәге үзара бәйләнешне оештыру нигезендә өстәмә белем бирүнең эчтәлеген, формаларын һәм технологияләрен яңарту;

• укучыларны районның барлык мәдәни-белем бирү ресурсларын, алдынгы Россия һәм халыкара тәҗрибәсен кулланып, өстәмә белем бирү өлкәсенә җәлеп итү;
• шәһәр дәрәҗәсендәге олимпиада, конкурслар, смотр, ярышлар призерлары һәм (яки) җиңүчеләр булган балалар санын арттыру өчен шартлар тудыру;
• тирәнтен өйрәнү дәрәҗәсендәге өстәмә белем бирү программаларын эшкәртү һәм иңдерү;
2) районда хемәтләрнең база пакетын тәэмин итүче өстәмә белем бирүнең вариатив модельләрен гамәлгә ашыру, өстәмә белем бирүнең эчтәлеген халыкның ихтыяҗлары һәм район үсеше бурычлары нигезендә яңарту, ә төгәлрәк:
• өстәмә белем бирү өлкәсендә хезмәт күрсәтү моделен эшкәртү һәм гамәлгә ашыру, шул исәптән, сәләтле балалар һәм социаль яктан якланмаган гражданнар өчен, сәламәтлеге чикләнгән балалар өчен һәм инклюзив өстәмә белем бирү өчен;
• өстәмә белем бирү системасының инновацияле потенциалын гамәлгә ашыру өчен белем бирү кластерларын булдыру;
• өстәмә белем бирү буенча белем бирү хезмәтләрен күрсәтүгә шәхси оешмаларны җәлеп итү өчен шартлар тудыру;
• белем бирүнең, каникул вакытында балаларны ял иттерү һәм сәламәтләндерүнең заманча модельләрен эшкәртү һәм иңдерү.
4) мәгълүмати, телекоммуникацион технологияләр, иҗади үсеш технологияләре, үзлегеңнән өйрәнүне иңдерү; дистанцион, читтән торып, көндезге-читтән торып белем алу формаларын иңдерү;
5)академик һәм иҗади сәләтлелеккә ярдәм итү формаларын үстерү.

***3.Дәүләт ярдәме һәм инвестицияле җәлеп итүчәнлекне арттыру хисабына балаларга өстәмә белем бирүнең заманча инфраструктурасын булдыру.***

Дәүләт белем бирү сәясәте белем бирү оешмасының тышкы кыяфәте формасы буенча да, эчтәлеге буенча да үзгәрергә тиешлегенә ориентлаштыра.
Өстәмә белем бирүнең заманча инфраструктурасын формалаштыру балаларның шәхси ихтыяҗларын тәэмин итүгә, компетентлы, шәхси ориентлашкан якын килүгә юнәлтелгән булырга тиеш, бу белем бирү процессын заманча белем бирү чаралары белән тәэмин итүне, шулай ук балаларны укытуның уңайлы һәм имин шартларын тудыруны күздә тота.
Әлеге юнәлешне гамәлгә ашыру шул исәптән үз эченә ала:
1) заманча махсуслашкан җиһаз сатып алу һәм техник юнәлешне үстерү өчен инфраструктура булдыру: робототехника, хореография, полилингваль белем бирү, театраль эшчәнлек, юл хәрәкәте кагыйдәләре, физкультура һәм спорт;
2) әлеге юнәлешләр буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыру өчен шәһәрнең социаль-мәдәни мохитыннан максималь файдалану;
3) заманча мәгълүмати һәм телекоммуникацияле технологияләрне иңдерү нигезендә өстәмә белем бирүгә мәгълүмати озатып йөрүне камилләштерү;

***4. Инновацияле активлыкны һәм иҗади инициативаны, шәхси үсешне һәм педагогик хезмәткәрләрнең үз-үзләрен үстерүләренә стимул бирүче корпоратив культура формалаштыру аша балаларга өстәмә белем бирүдә кадрлар потенциалын үстерү.***

Кадрлар потенциалын үстерүгә һәм балаларга өстәмә белем бирү өлкәсендәге педагогик һәм җитәкче хезмәткәрләрнең социаль статусын күтәрүгә юнәлтелгән чаралар балаларга өстәмә белем бирүне яңарту һәм үстерүгә ярдәм итүгә ярдәм итәчәк квалификацияле кадрлар килүгә ярдәм итәргә чакырылган.

Әлеге юнәлешне гамәлгә ашыру шул исәптән түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) районның өстәмә белем бирү системасында эшләүче педагогик хезмәткәрләрнең социаль статусын күтәрү, балаларга өстәмә белем бирүче педагогик һәм җитәкче хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү механизмын, өстәмә белем бирүдә сәләтле балалар һәм компетентлы педагогик хезмәткәрләрне саклап калу өчен рухи һәм матди стимул системасын камилләштерү;

2) балаларга өстәмә белем бирү өлкәсенә яшь белгечләрне җәлеп итү һәм аларга ярдәм итү системасын булдыру, балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләренең җитәкче вазыйфаларына потенциаль кандидатлар резервын булдыру; кандидатларга бәя бирү һәм иң яхшыларны сайлап алу;

3) өстәмә белем педагогларының һәм белгечләренең квалификациясен алдан узып күтәрү системасын эшкәртү;

4) педагогик кадрларның фәнни-методик озатып йөрү системасын үстерү һәм белгечләр өчен электрон укыту, методик, фәнни, белешмәле базасын булдыру;

5) өстәмә белем бирү үсешенә ярдәм итүче һөнәри-иҗтимагый экспертларның һөнәри коалициясен формалаштыру;

6) балаларга өстәмә белем бирүче педагоглар өчен фәнни, укыту-методик һәм белешмәле әдәбият, вактылы матбугатны кертеп укыту-методик әдәбият виртуаль һәм электрон китапханә булдыру.

### *5. Балаларга өстәмә белем бирү системасының ресурс потенциалын камилләштерү*

Балаларга өстәмә белем бирү системасын үстерү оештыру, кадрлар, фәнни, программа-методик, матди-техник характердагы тулы бер бурычларның уңышлы хәл ителүенә бәйле.

Балаларга өстәмә белем бирү системасы үсешенә бүлеп бирелгән чараларны сарыф итүнең нәтиҗәле юлларыннан файдаланырга, бу төр белем бирүгә адреслы ярдәм итү системасын булдырырга кирәк.

Әлеге юнәлешне гамәлгә ашыру шул исәптән түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) балаларга өстәмә белем бирүгә норматив финанслау механизмнарын үстерү, балаларга өстәмә белем бирүдә нәтиҗәле икътисадый мөнәсәбәтләр формалаштыру;

2) бюджеттан тыш чараларны җәлеп итү механизмнарын камилләштерү, балаларга өстәмә белем бирү оешмалары тарафыннан бюджеттан тыш чараларны җәлеп итүне норматив-хокукый җайга салуның социаль-икътисадый чараларын эшкәртү, өстәмә белем бирү хезмәтләре өчен кулланучыларның түләүләрен легальләштерү;

3) бюджет акчалары хисабыннан күрсәтелә торган өстәмә белем бирү буенча белем бирү хезмәтләре күләмен арттыру;

4) өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларының белем бирү хезмәтләре спектрын киңәйтү һәм матди-техник базаны яңарту өчен шәхси инвесторларны җәлеп итү;

5) җиһаз һәм йорт җиһазын сатып алу, янгынга каршы чаралар комплексын гамәлгә ашыру.

## Программаның этаплары һәм гамәлгә ашыру планы

| № | Эшчәнлек эчтәлеге | Башкаручылар | Чама белән сроклары |
|---|---|---|---|
| **2019 ел 1 этап** | | | |
| 1 | Паспортны, проект планын раслау, | Минзәлә муниципаль | Октябрь, 2019 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | финанслау чыганакларын һәм механизмнарны билгеләү | район Башкарма комитеты | |
| 2 | Проектның эшче төркемен формалаштырырга | Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты | Ноябрь, 2019 |
| 3 | Муниципаль районда аерым юнәлешләрне үстерү буенча хезмәттәшлек турында өстенлекле проектта катнашучы һәм партнерлар арасында килешүләр төзү | Минзәлә муниципаль районының "Мәгариф бүлеге" МКУ | Ноябрь, 2019. |
| | Өстәмә белем бирүнең төрле дәрәҗәдәге программаларын эшкәртү һәм иңдерү, шул исәптән, авыл җирлегендә яшәүче балалар өчен дә (тиешле дәрәҗәләр буенча Программалар)<br>«Белем бирүдә робототехника» моделе<br>«Полилингваль белем бирү» моделе<br>«Физкультура һәм спорт» моделе;<br>«Хореография» моделе<br>«Театраль эшчәнлек» моделе<br>«ПДД» моделе | Минзәлә муниципаль районының "Мәгариф бүлеге" МКУ, төрле типтагы оешмалар, шул исәптән, һөнәри белем бирү учреждениеләре тарафыннан | октябрь-ноябрь, 2019 |
| | Челтәрле үзара бәйләнеш формасында хезмәттәшлек программасын эшкәртү һәм гамәлгә ашыру | Белем бирү оешмалары һәм һөнәри белем бирүче оешмалар арасында, шул исәптән, спорт һәм мәдәният, иҗтимагый оешмалар арасында | ноябрь-декабрь, 2019 |
| | Педагогларны кабаттан әзерләү, квалификацияне күтәрүне һәм һөнәри яктан кабаттан әзерләүне уздыру | «Мәгариф бүлеге» МКУ Һөнәри белем бирү оешмалары | Бөтен чор дәвамында |
| **2020 ел 2 этап** | | | |
| | Юнәлешләр буенча пилот проектларын Гамәлгә ашыру һәм Озатып йөрү:<br>«Белем бирү буенча робототехника» моделе<br>«Инглиз теле» моделе<br>«Физкультура һәм спорт» моделе;<br>«Хореография» моделе<br>«Театраль эшчәнлек» моделе;<br>«ПДД» моделе | | |
| | Сәләтле балаларны ачыклау һәм ярдәм итү | Районның мәгариф бүлеге | Бөтен чор дәвамында |
| | WorldSkills һөнәри чемпионатында катнашуга балаларда һөнәри ориентация формалаштыру | | |
| | Төрле дәрәҗәдәге конкурсларда, олимпиадаларда катнашу | | |
| | Өстәмә белем бирү өлкәсендә белем бирү хезмәтләренең бердәм мәгълүмати базасын формалаштыру | | |
| | Инфраструктураны, җиһазларны һәм өстәмә белем бирү чараларын яңарту | | |
| | Балаларга өстәмә белем бирү | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | учреждениеләре базасында проектлауны, заманча инновацияле технологияләрне җәлеп итеп, педагоглар белән актив методик эшнең төрледән-төрле формаларын уздыру | | |
| | Төбәктә һәм конкурс хәрәкәтендә инновацияле эшчәнлектә катнашырга балаларга өстәмә белем бирү бүлекләре булган гомуми белем бирү оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләренең педагогик һәм идарә итү хезмәткәрләренә стимул бирү. | | |
| | - белем бирү программалары буенча өстәмә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының лицензия алуы | | |
| **2021 ел 3 этап** | | | |
| | Гамәлгә ашыруның барлык этапларында гомуми белем бирүче өстәмә программаларның үтәлеш мониторингы | “Мәгариф бүлеге” МКУ | |
| | Өстенлекле проектны гамәлгә ашыру нәтиҗәләрен чыгару | | |

**Программаны гамәлгә ашыру механизмы**

1. Программаны гамәлгә ашыру җаваплы башкаручы һәм Программаны бергәләп үтәүчеләр белән берлектә гамәлгә ашырыла.

2. Программаның үтәлешенә җаваплы зат:

1) Программа проектын эшкәртүне, аны бергәләп башкаручылар белән килешшенүне тәэмин итә;

2) Программа структурасын, шулай ук бергәләп үтәүчеләр исемлеген формалаштыра;

3) Программаны бергәләп башкаручылар белән берлектә чараларны үтәүнең мөмкин булган срокларын, финанслау күләмен һәм чыганакларын килешенә;

4) Программага экспертиза уздыруны билгеләнгән тәртиптә тәэмин итә;

5) Программаның үтәлеше өчен кирәкле норматив хокукый актларны үз вәкаләтләре чикләрендә эшкәртә;

6) Программаны гамәлгә ашыруны оештыра, Программа күрсәткечләренең максатчан күрсәткечләренә ирешү, шулай ук гамәлгә ашыруның ахыргы нәтиҗәләрен кертә һәм җаваплылык тота;

7) чираттагы финанс елына һәм план чорына программа чаралары исемлеген әзерли һәм аныклый, программа чаралары буенча чыгымнарны, шулай ук Программаны гамәлгә ашыру механизмын аныклый;

8) Программага үзгәрешләр кертү өчен барлык кирәкле барлык документларны (йомыш язуы, район бюджетыннан бюджет асигнованиеләре бүлеп бирүгә (аныклауга) заявка) әзерли;

9) Программаның үз вакытында һәм сыйфатлы үтәлеше өчен җаваплылык тота, идарә итүне гамәлгә ашыра, аны гамәлгә ашыруга бүлеп бирелә торган чаралардан максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тәэмин итә;

10) Программаны гамәлгә ашыру барышы һәм финанс чараларыннан файдалану барышы турында отчет әзерли;

11) Программаның үтәлешен контрольдә тота.

3. Программаны бергәләп башкаручылар:
1) үз компетенциясе чикләрендә Программа чараларын гамәлгә ашыруны башкара;
2) программа чараларының сыйфатлы һәм нәтиҗәле үтәлеше, аларны гамәлгә ашыру өчен бүлеп бирегән чаралардан нәтиҗәле һәм максатчан файдалану өчен җаваплылык тоталар;
3) үз вәкаләтләре чикләрендә Программа чаралары үтәлеше өчен кирәкле норматив-хокукый актларны эшкәртәләр;
4) Программа чараларының финанслау күләмен, аны гамәлгә ашыру механизмын, шулай ук чираттагы финанс елына һәм план чорына программа чаралары исемлеген аныклау (үзгәртү) буенча тәкъдимнәрне җаваплы башкаручыга җибәрә;
5) Программа чараларын гамәлгә ашыру барышы һәм финанслау чыганаклары киселешендә финанс чараларыннан файдалану турында җаваплы башкаручыга тапшыралар.
4. Программаның үтәлеше иң беренче чиратта, Минзәлә муниципаль районы бюджеты ресурслары, шулай ук сыйфатлы күрсәткечләр һәм индикаторлар буенча Программаны гамәлгә ашыру барышын идарә итүнең нәтиҗәлелеге белән билгеләнәчәк үзвакытында һәм стабиль финанслауга бәйле.

**Программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә:**

- Балаларга өстәмә белем бирү программалары белән 5-8 яшьлекләрне колачлау 85%ка җитәчәк (өстәмә белем хезмәтләре алучы балаларның 5-8 яшьлек гомуми балалар санына чагыштырмача авырлыгы);

•халыкның балаларга өстәмә белем бирү хезмәтләренең сыйфаты белән канәгатьләнүе артчак;

балаларга өстәмә белем бирү программалары җыелмасы һәм структурасы балалар белән эшчәнлекнең төрледән-төрле төрләре һәм формаларын эшләп карау мөмкинлеге, шулай ук шәхси белем бирү траекторияләре кысаларында максималь мобильлекне тәэмин итәчәк;

- Гаиләләр балаларга өстәмә белем бирү оешмаларына, хезмәтләренә һәм программаларга керү мөмкинлегенә ия булачак;
- балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында белем алучыларның тикшеренү, фәнни-техник, проект-конструкторлык эшчәнлегенең заманча программаларын гамәлгә ашыру өчен шартлар тудырылачак;
- эшчәнлекнең югары нәтиҗәләрен күрсәтүче өстенлекле юнәлешләр (техник иҗат, хореография, полилингваль белем бирү, театралҗ һәм спорт эшчәнлеге, юл йөрү кагыйдәләре) буенча балаларга өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы өстәмә белем бирү педагогларының һәм әйдәп баручы оешмаларына ярдәм тәэмин ителәчәк;
- балаларга өстәмә белем бирү өчен каникуллар вакытында потенциалдан файдалануның нәтиҗәле механизмнары кертеләчәк;
- системалы рәвештә физик культура һәм спорт, техник иҗат, хореография белән шөгыльләнүче балаларның, социаль проектларда, җәмәгать эшчәнлегендә. Фестиваль-конкурс хәрәкәтендә, җәйге чорда эшкә урнашу мөмкинлеге булганнарга профильле ориентлашу программаларында катнашучы мәктәп укучыларның социальләшүендә куркынычларны киметүгә юнәлтелгән инновацияле белем бирү программаларына кертелгән балалар санын арттыру.

**Мөмкин булган хәвеф-хәтәр:**

-аерым программа чараларына чыгымнарны арттыру;

-программа чаралары кысаларында күрсәтү күздә тотылган хезмәтләрнең аерым төрләренә бәяләр арту һәм нәтиҗә буларак, аерым программа чараларына чыгымнарның артуы;
-кадрлар, матди-техник һәм методик тәэмин ителеш җитәрлек булмау аркасында программа бурычларын гамәлгә ашыру мөмкин булмау;
-аны яңадан торгызу экстрен чаралар кабул итүгә китерергә мөмкин булган өстәмә белем бирүнең матди инфраструктурасы таушалу;
-өстәмә белем бирү учреждениеләрен үзгәртеп кору һәм оптимальләштерү, өстәмә белем алучы белем алучылар санының кимүе;
-хезмәт хакы түбән булу сәбәпле, өстәмә белем бирү учреждениеләреннән педагогик кадрларның (аеруча ир-атларның) китүе.

## ***“Белем бирүдә робототехника” подпрограммасын гамәлгә ашыру моделе***

Мәгариф системасында инновацияле процесслар гомумән алганда системаны яңадан оештыруны таләп итә, мәктәпкәчә белем һәм тәрбия бирүгә аерым мәгънә бирелә, чөнки нәкъ шушы чорда баланың шәхес буларак формалашуына барлык фундаменталь компонентлар салына.

Мәктәпкәчә яшьтәгеләргә белем бирү, шулай ук иҗади, танып белү эшчәнлеге үсешенә мотивация формалаштыру - ФГОС кысаларында бүгенге көндә педагоглар алдында торган мөһим бурычлар шундый. Бу катлаулы бурычлар, иң беренче чиратта, белем бирүдә үзенчәлекле шартлар булдыруны таләп итә, шуңа бәйле рәвештә, конструкторлар белән эшләүгә зур әһәмият бирелә.

Балалар бакчасында конструкторлар белән эшләү һәрчак булды, әмма әгәр дә элек конструктив фикер йөртү һәм вак моториканы үстерүгә өстенлек бирелгән булса, хәзер яңа стандартлар нигезендә яңача якын килү зарур.

Лего-конструктор һәм робототехниканы иңдерүнең актуальлеге өстәмә белем бирүдә ФГОС иңдерү җирлегендә әһәмиятле, чөнки:

Мәктәпкәчә яшьтәгеләрнең интеллектуаль үсеше өчен бик яхшы чара булып тора; педагогка уен режимында мәктәпкәчә яшьтәгеләрнең үсешен, белем һәм тәрбияне берләштерү мөмкинлеге бирә (*уен барышында укырга һәм өйрәнергә*);

Тәрбияләнүчегә эшчәнлекнең төрле төрләрендә – уенда. Аралашуда. Конструктор белән эшләгәндә инициатива һәм мөстәкыйльлек күрсәтү мөмкинлеге бирә һ.б.лар;

уенны тикшеренү һәм экспериментлау эшчәнлеге белән берләштерә. Балага экспериментлау һәм чикләре булмаган үз хосусый дөньясын булдыру мөмкинлеге бирә.

Балалар бакчасында конструктор белән эшләү төрле яшьтәге балалар белән, аңлаешлы уен формасында, гадидән – катлаулыга принцибы буенча уздырыла.

Конструктор баш һәм кулларны бер үк дәрәҗәдә эшләүгә уята, бер үк вакытта баш миенең ике ярымшары да эшли, бу баланың төрле яклап үсешендә чагыла. Бала үзенең телдән исәпли алуын, сан составын, гади арифметик гамәлләр башкаруын сизми дә кала. Һәрвакыт үзеннән-үзе төрле ситуацияләр тудырыла: бала үзенең мавыгып төзүе турында сөйли, чөнки ул үзенең хәзинәсе турында һәркем белүен тели – болар барысы да сөйләм теленең үсеше һәм халык алдында җиңел һәм иркен сөйли белүне формалаштыра.

**Программа максаты:**

«ROBOlab» конструктор белән эшләү, модельләштерү һәм робототехника лабораториясе эше кысаларында Минзәлә муниципаль районының мәктәпкәчә яшьтәге балаларының конструкторлык сәләтләрен формалаштыру һәм үстерү өчен кирәкле шартларны тудырырга кирәк.

**Программаның төп бурычлары түбәндәгеләр:**

1. Балаларда танып белү һәм тикшеренү активлыгы, фикерләү эшчәнлегенә омтылыш формалаштыра.

2. Кулларның вак моторикасын, эстетик зәвыгын, конструктив күнекмәләр һәм белемнәрне үстерү.

3. Парлап, коллективта эш барышында балаларның коммуникатив күнекмәләрен, бурычларны дөрес бүлүне камилләштерү.

**Программаны үзләштерүнең көтелгән нтиҗәләре:**

- балада тикшеренү һәм иҗади-техник эшчәнлек белән кызыксыну уяна, өлкәннәргә һәм яшьтәшләренә сораулар бирә, сәбәпле-тикшерү элемтәләре белән кызыксына, техник бурычларга аңлатмаларны мөстәкыйль уйларга маташа; күзәтергә, экспериментлар ясарга омтыла;

- баланың күзаллавы үсеш алган, бу тикшеренү һәм иҗади-техник эшчәнлекнең төрле төрләре, төзелеш уенында һәм конструктор белән эшләүдә гамәлгә ашырыла; педагог ярдәме белән эшләнгән схема буенча, төрле роботлар өчен компьютерда программалар җибәрә;

- бала яшьтәшләре һәм өлкәннәр белән актив аралаша, бергәләп конструктор белән эшләүдә, техник иҗатта катнаша, төрле мәгълүмат чаралары белән эш күнекмәләренә ия;

-бала педагог ярдәмендә эшләнгән схема буенча LEGO WeDo конструкторының төп компонентлары, төп төшенчәләр белән таныш, роботлар өчен компьютерда программаларны җибәрә;

